Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2005 елның 23 июнендә
кабул ителде

1 статья. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, №6-7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, №10 (8); 2003, №5), түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында

Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария эшен оештыруның һәм гамәлгә ашыруның бердәм принципларын билгели.

1 бүлек. **ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР**

1 статья. **Татарстан Республикасында ветеринария эше**

Ветеринария эше дигәндә, җәмгыять ихтыяҗлары өчен ветеринария ягыннан сыйфатлы һәм хәвефсез терлекчелек продукциясе алу, кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулардан халыкны саклау максатларында

терлекләрнең сәламәтлеген саклап калу һәм ныгыту гамәлләре комплексын гамәлгә ашыру аңлашыла.

2 статья. **Татарстан Республикасында ветеринария эшен хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында ветеринария эшен хокукый җайга салу федераль законнар, әлеге Закон һәм башка норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукы**

1. Ветеринария эше белән шөгыльләнү хокукына ветеринария эше өлкәсендәге югары яисә урта ветеринария белемле белгечләр ия була.

2. Ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр үзләренең һөнәри эшчәнлегендә Россия Федерациясе ветеринария законнарына, әлеге Законга һәм башка хокукый норматив актларга таяна.

3. Ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнүнең билгеләнгән нормаларын һәм кагыйдәләрен бозган өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә җаваплы булалар.

4 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасында ветеринария эшен законнар белән җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагына түбәндәгеләр керә:

- ветеринария эше өлкәсендә норматив хокукый актлар әзерләү һәм кабул итү, дәүләт идарәсен гамәлгә ашыру;

- дәүләт ветеринария хезмәтен нәтиҗәле оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү;

- йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм терлек авырулары куркынычы барлыкка килү һәм таралу очрагында Татарстан Республикасы территориясендә карантин яисә башка чикләүләр кертү һәм аларны юкка чыгару турында карарлар кабул итү.

3. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе карамагына кертелгән мәсьәләләрдән гайре, ветеринария өлкәсендәге мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә.

4. Татарстан Республикасы законы белән җирле үзидарә органнарына законнар нигезендә ветеринария эше өлкәсендә республика карамагындагы кайбер дәүләт вәкаләтләре бирелергә мөмкин.

2 бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ДӘҮЛӘТ ВЕТЕРИНАРИЯ ХЕЗМӘТЕ. ҖИТЕШТЕРҮ ВЕТЕРИНАРИЯ ХЕЗМӘТЕ. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ВЕТЕРИНАРИЯ ОЕШМАЛАРЫ. ХОСУСЫЙ ВЕТЕРИНАРИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ

5 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәтен оештыру**

1. Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәтенең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- терлекләрнең йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларын кисәтү һәм бетерү;
- терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария ягыннан иминлеген тәэмин итү;
- кеше һәм терлекләр өчен уртак булган авырулардан халыкны яклау;
- Татарстан Республикасы территориясен Татарстан Республикасына читтән терлек авырулары керүдән саклау.

2. Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәте системасына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы;

Республика ветеринария лабораториясе;

Терлекләр авыруларына каршы көрәш буенча республика станциясе;

төрле милек рәвешләрендәге ветеринария хезмәтләрен махсус ветеринария мөлкәте белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы республика ветеринария предприятиесе;

региональ ветеринария лабораторияләре;

районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре.

3. Татарстан Республикасында ветеринария эшенә җитәкчелек итүне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы гамәлгә ашыра.

4. Район (шәһәр) ветеринария хезмәтенә җитәкчелек итүне район (шәһәр) дәүләт ветеринария берләшмәсе гамәлгә ашыра. Район (шәһәр) дәүләт ветеринария берләшмәсе составына терлек авыруларына каршы көрәш станциясе, ветеринария лабораториясе, ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясе, ветеринария дәвалау йортлары, ветеринария участоклары һәм пунктлары, ветеринария даруханәләре, шулай ук

кошчылык фабрикаларында, терлек продуктларын һәм чималын эшкәртү, саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария контроле хезмәтләре керә.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы җитәкчесе – бер үк вакытта Татарстан Республикасы баш дәүләт ветеринария инспекторы, районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре җитәкчеләре бер үк вакытта районнарның һәм шәһәрләрнең баш дәүләт ветеринария инспекторлары булалар.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы җитәкчесе, Россия Федерациясенең баш дәүләт ветеринария инспекторы белән килештерелеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вазыйфасына билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә.

7. Районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре җитәкчеләре законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә вазыйфаларына билгеләнеп куелалар һәм вазыйфаларыннан азат ителәләр.

6 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы карамагына түбәндәгеләр керә:

1) барлык дәүләт ветеринария хезмәте учреждениеләренең эшчәнлегенә җитәкчелек итү;

2) ветеринария оешмаларын һәм ветеринария эше өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән белгечләрне тикшереп тору;

3) эпизоотиягә каршы гамәлләр һәм ветеринария-санитария гамәлләре комплексын уздыру буенча оешмаларның һәм гражданнарның эшчәнлеген координацияләү;

4) ветеринария эшен үстерүнең төп принципларын һәм стратегик юнәлешләрен эшләү, аның оештыру рәвешләрен камилләштерү;

5) терлекләрнең йогышлы һәм йогышлы булмаган авыруларын кисәтү гамәлләрен оештыру, терлекләрне аеруча куркыныч авырулардан яклау буенча республика программаларын эшләү;

6) терлекләрнең йогышлы һәм массакүләм йогышлы булмаган авырулары куркынычы барлыкка килү һәм таралу очрагында Татарстан Республикасы территориясендә карантин һәм башка чикләүләрне кертү һәм аларны юкка чыгару турында тәкъдимнәр әзерләү;

7) терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын радиоактив, техноген һәм башка зарарлы йогынтылардан ветеринар яклау буенча республика программаларын әзерләү;

8) авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм башка оешмаларда, крестьян (фермер) хуҗалыкларында ветеринария-дәвалау эшләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру;

9) биологик препаратларга һәм терлекчелекнең ветеринария иминлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка матди-техник чараларга республика заказларын булдыру;

10) биологик, дәвалау, дезинфекцияләү препаратларының һәм гадәттән тыш хәлләрдә эпизоотиягә каршы кичектергесез һәм ветеринария-санитария гамәлләрен уздыру өчен кирәкле башка матди-техник чараларның республика резервын булдыру һәм бүлү;

11) ветеринария исәбен һәм хисабын, терлекләрнең авыруларын, ветеринария гамәлләренең нәтиҗәлелеген статистик анализлауны оештыру;

12) дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру;

13) терлекләрдән һәм үсемлекчелектән алынган азык-төлек продуктларын ветеринария-санитария һәм экология ягыннан тикшереп торуны уздыру.

7 статья. **Дәүләт ветеринария күзәтчелеге**

1. Дәүләт ветеринария күзәтчелеге – дәүләт ветеринария инспекторларының ветеринария законнарын бозуларны булдырмауга, ачыклауга һәм кисәтүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге.

2. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген федераль законнар нигезендә һәм аларда билгеләнгән тәртиптә урындагы затлар гамәлгә ашыра.

8 статья. **Дәүләт ветеринария инспекторларының хокуклары һәм бурычлары**

Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы, районнарның һәм шәһәрләрнең баш дәүләт ветеринария инспекторлары һәм аларның район, шәһәр ветеринария лабораторияләре башлыклары (директорлары) булып торучы урынбасарлары, алар житәкләүче ветеринария дәвалау пунктларына, ветеринария пунктларына хезмәт күрсәтүче территорияләрнең баш ветеринария инспекторлары һәм дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле башка затлар үз хокукларын федераль закон нигезендә башкаралар.

9 статья. **Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урындагы затларның һәм дәүләт ветеринария хезмәте оешмаларының эшчәнлеге гарантияләре**

1. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урындагы затлар башкарма хакимиятнең тиешле органнары вәкилләре булалар, дәүләт

яклавында торалар, үз эшчәнлекләрендә бәйсез булалар һәм законнарга таянып эш итәләр.

2. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урындагы затларга аларның законлы эшчәнлегенә тоткарлык ясау максатында дәүләт органнары, урындагы затлар, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан йогынты ясау законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

10 статья. **Җитештерү ветеринария хезмәте**

Эшкәртүче авыл хуҗалыгы оешмалары һәм башка оешмалар үз акчалары исәбенә җитештерү ветеринария хезмәтен булдыра алалар.

11 статья. **Җирле үзидарәнең ветеринария оешмалары**

Җирле үзидарә органнары ветеринария оешмаларын булдыра алалар. Җирле үзидарә органнары белән алар оештыра торган ветеринария оешмалары арасындагы мөнәсәбәтләр законнар нигезендә җайга салына.

12 статья. **Хосусый ветеринария эшчәнлеге**

Ветеринария эшчәнлеге белән хосусый милектәге мөлкәте булган оешмалар, шулай ук индивидуаль эшкуарлар законнар нигезендә шөгыльләнә ала.

13 статья. **Ветеринария законнарын бозган өчен җаваплылык**

Урындагы затлар, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар ветеринария законнарын бозган өчен законнар нигезендә дисциплинар, административ һәм җинаять җаваплылыгына җәлеп ителәләр.

3 бүлек. ТЕРЛЕК АВЫРУЛАРЫН КИСӘТҮГӘ ҺӘМ БЕТЕРҮГӘ, ТЕРЛЕКЧЕЛЕК ПРОДУКЦИЯСЕНЕҢ ВЕТЕРИНАР ИМИНЛЕГЕН ТӘЭМИН ИТҮГӘ КАРАТА ГОМУМИ ТАЛӘПЛӘР

14 статья. **Терлекчелек продукциясен җитештерү предприятиеләрен планлаштыру һәм төзү**

1. Терлекчелек комплексларын, кошчылык фабрикаларын, ит комбинатларын, терлекчелек продуктларын җитештерү һәм саклау буенча башка предприятиеләрне, крестьян (фермер) хуҗалыкларын һәм гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларын планлаштыру һәм төзү терлекләрне асрау һәм терлекчелек продуктларын җитештерү өчен, җитештерү калдыклары белән һәм терлекләрнең йогышлы авыруларын

кузгатучылар белән әйләнә-тирә мохитне пычранудан саклау өчен аеруча уңай шартлар тудыруны күз алдында тотарга тиеш.

2. Төзелеш өчен җир кишәрлеген бирү, терлекчелек продуктларын җитештерү һәм саклау предприятиеләрен төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм эксплуатациягә тапшыру документларын раслау проект документациясенең гамәлдәге ветеринария нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килүләре турында дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнарының бәяләмәләре булганда гына рөхсәт ителә.

15 статья. **Терлекләрне асрау, ашату һәм эчертү, аларны бер урыннан икенче урынга күчерү яисә куу**

1. Терлекләрне вакытлыча яисә даими асрау өчен билгеләнгән урыннар үзенең мәйданы һәм җайланмалары буенча терлекләрнең сәламәтлеге өчен уңай шартлар тәэмин итәргә тиеш.

2. Терлекләрнең хуҗалары булган оешмалар һәм гражданнар аларны ветеринария–санитария таләпләренә һәм нормаларына туры килерлек азык һәм су белән тәэмин итәргә тиеш.

3. Билгеләнгән ветеринария–санитария таләпләренә һәм нормаларына туры килмәслек азык һәм азыкка өстәлмәләр, шул исәптән традицион булмаганнары да, баш дәүләт ветеринария инспекторы яисә аның урынбасары карары буенча җитештерүдән кире алына яисә сатудан алына.

4. Терлекләрне бер урыннан икенче урынга күчерү яисә куу дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнары белән килешенгән маршрутлар буенча һәм терлекләрнең авыруларын барлыкка килүне һәм таратуны кисәтү таләпләрен үтәгән килеш башкарылырга тиеш.

16 статья. **Терлекчелек продукциясен әзерләү, эшкәртү, саклау, ташу һәм сату**

1. Ветеринария-санитария экспертизасы нәтиҗәләре буенча терлекчелек продуктлары халык өчен билгеләнгән иминлек таләпләренә туры килергә һәм терлекләрнең йогышлы авыруларыннан имин территориядән кертелгән булырга тиеш.

2. Терлекчелек продукциясен әзерләү, эшкәртү, саклау, ташу һәм сату белән шөгыльләнүче оешмалар һәм гражданнар әлеге таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

17 статья. **Терлекләрнең йогышлы һәм массакүләм йогышлы булмаган авырулары барлыкка килү һәм таралу куркынычы килеп туганда башкарма хакимият органнарының һәм дәүләт ветеринария хезмәте урындагы затларының бурычлары**

1. Татарстан Республикасының билгеле бер территориясендә һәм торак пунктларында терлекләрнең йогышлы һәм массакүләм булмаган йогышлы авырулары килеп чыгу һәм таралу куркынычы барлыкка килгәндә үзләре хезмәт күрсәтү өчен беркетелгән территорияләр буенча баш дәүләт ветеринария инспекторлары, аларның урынбасарлары тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан чикләү гамәлләре (карантин) кертелә.

2. Терлекләрнең йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларын таратуны һәм чыганакларын юкка чыгаруны кисәтү буенча юридик һәм физик затларның эшчәнлегенә оператив житәкчелек итү һәм жайга салу өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләнгән тәртиптә махсус комиссияләр төзи.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты терлекләрнең йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулары чыганакларын юкка чыгаруның ветеринария законнарында каралган махсус чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

4. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар терлекчелек калдыкларын жыю, утильләштерү, юкка чыгару буенча ветеринария-санитария кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне контрольдә тота.

5. Терлекләрнең йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулары килеп чыгу һәм таралу куркынычы барлыкка килгәндә жирле үзидарә органнары вазыйфалары федераль закон белән билгеләнә.

18 статья. **Терлек хужаларының һәм терлек продукциясе житештерүчеләрнең бурычлары**

1. Терлек хужалары һәм терлек продукциясе житештерүчеләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- терлекләрне асрауга, терлекчелек продуктларын житештерүгә, эшкәртүгә, саклауга һәм сатуга бәйле объектларны урнаштырганда, төзегәндә, файдалануга тапшырганда зоогигиена һәм ветеринария–санитария таләпләрен үтәргә;

- ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр таләбе буенча тикшерү өчен терлекләрне аларга китерергә, терлекләрнең кинәт кенә үлү очраклары яисә терлекләрнең берьюлы массакүләм авырулары хакында кичекмәстән шушы белгечләргә хәбәр итәргә, авыру ихтималы булган терлекләрне изоляциләү чараларын күрергә;

- терлекләрне күчерүнең һәм чалуның, терлекчелек продуктларын эшкәртүнең, саклауның һәм сатуның билгеләнгән ветеринария-санитария кагыйдәләрен үтәргә;

- терлекләрнең авыруларын кисәтү һәм аларга каршы көрәш гамәлләре турында һәм башка ветеринария мәсьәләләре буенча ветеринария белгечләренең таләпләрен үтәргә.

2. Терлекләрнең сәламәтлеге, аларны асрау һәм алардан файдалану өчен - аларның хуҗалары, ә ветеринария–санитария ягыннан имин терлекчелек продуктлары чыгару өчен шушы продуктларны җитештерүчеләр җаваплы була.

19 статья. **Терлекләрне аерып алу һәм терлекчелек продукциясен тартып алу**

1. Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк итү һәм терлекчелек продукциясен тартып алу федераль законда билгеләнгән тәртиптә башкарылырга мөмкин.

2. Терлекләрне аерып алу яисә терлекчелек продукциясен тартып алу рөхсәт ителерлек авыруларның исемлеге федераль законда билгеләнгән тәртиптә билгеләнә.

3. Әйләнештән алынган сыйфатсыз һәм куркыныч продуктлар һәм чимал утильләштерү яисә юкка чыгару мөмкинлеген билгеләү йөзеннән дәүләт ветеринария күзәтчелеге учреждениеләре тарафыннан ветеринария-санитария экспертизасы үтәргә тиеш.

4. Хуҗасы килеп чыгышын раслый алмаган, шулай ук сыйфатсызлык билгеләре күзгә ташланып торган һәм кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан–туры янаучы терлекчелек продуктлары һәм чималы экспертиза үткәрмичә генә утильләштерелергә яисә юк ителергә тиеш. Мондый продуктларны утильләштергәнче яисә юк иткәнче аларның хуҗасы дәүләт ветеринария күзәтчелеге вәкиле барында продуктларның һәм чималның киләчәктә билгеләнеше буенча куллану ихтималын теләсә нинди мөмкин һәм ышанычлы алым белән юкка чыгарырга тиеш.

5. Терлекчелекнең сыйфатсыз продуктлары һәм чималы аларга экспертиза үткәрү өчен кирәкле чорга вакытлыча саклауга җибәрелә. Экспертиза нәтиҗәләре буенча дәүләт ветеринария күзәтчелеге учреждениеләре куркыныч продуктларны һәм чималны утильләштерү яисә юк итү турындагы карар кабул итәләр һәм аларны утильләштерүне һәм юк итүне тикшереп торалар.

6. Оешмалар һәм гражданнар терлекләрне аерып алу яисә терлекчелек продукциясен тартып алу нәтиҗәсендә үзләренә китерелгән зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда түләттерергә хокуклы.

20 статья. **Терлекчелек продукциясенә ветеринария-санитария экспертизасы**

1. Ит, ит продуктлары һәм терлек чалганнан соң калган башка продуктлар, сөт, сөт продуктлары, йомырка, балык һәм башка терлекчелек

продуктлары ветеринария-санитария ягыннан иминлекләрен һәм азык-төлек максатларында яраклылыгын билгеләү өчен ветеринария-санитария эксперизасы үтәргә тиеш.

2. Ветеринария-санитария экспертизасын оештыру һәм үткәрү, аның нәтиҗәләрен бәяләү тәртибе һәм терлекчелек продуктларын азык максатларында файдалану шартлары, шушы нәтиҗәләргә карап, ветеринария законнары үсеше йөзеннән чыгарылучы ветеринария кагыйдәләре белән билгеләнә. Бу кагыйдәләр ветеринария-санитария нормативларын урнаштыралар, оешмалар һәм гражданнар житештерә торган, сата торган, шулай ук сәүдә предприятиеләре тарафыннан базарларда сатылучы терлекчелек продукциясе шушы кагыйдәләргә туры килергә тиеш.

3. Билгеләнгән тәртиптә ветеринария-санитария экспертизасы үтмәгән итне, сөтне һәм терлекләрдән алынган башка азык-төлек продуктларын сату һәм ашамлык итеп куллану тыела.

4. Күн, мех һәм терлекчелекнең башка чималын эшкәртү, куллану тәртибе ветеринария-санитария кагыйдәләре белән билгеләнә.

4 бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ДӘҮЛӘТ ВЕТЕРИНАРИЯ ХЕЗМӘТЕН МАТДИ–ТЕХНИК ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ

21 статья. **Дәүләт ветеринария хезмәтен финанслау**

1. Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәтен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шулай ук законнар нигезендә башка акчалар була.

2. Терлекләрнең йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулары килеп чыгу урыннарын юк итү гамәлләре дәүләт ветеринария хезмәте органнары тарафыннан расланган исемлек буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән ассигнованиеләр исәбеннән башкарыла.

3. Авыл хужалыгы оешмаларына, крестьян (фермер) һәм гражданнарның шәхси хужалыкларына дәүләт ветеринария хезмәте оешмалары тарафыннан күрсәтелүче ветеринария ярдәме өчен, шулай ук терлекләрне чалу, терлекчелек продуктларын һәм чималын эшкәртү, әзерләү һәм саклау предприятиеләрендәге ветеринария гамәлләре өчен шартнамә нигезендә түләнә. Бу чакта дәүләт ветеринария учреждениеләрен тотуга бүлеп бирелүче бюджет ассигнованиеләре тулысынча сакланып кала.

22 статья. **Ветеринария тәэминаты**

1. Ветеринария һәм авыл хужалыгы оешмаларын, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария белгечләрен махсус

ветеринария мөлкәте белән тәэмин итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы карамагындагы республика ветеринария унитар предприятиесенә йөкләнә.

2. Ветеринария препаратлары, җайланмалар, кораллар белән оператив тәэмин итү максатларында район ветеринария берләшмәләре составында һәр районда ветеринария аптекалары ачыла.

3. Ветеринария һәм авыл хуҗалыгы оешмаларын, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария белгечләрен ветеринария препаратлары, кораллары һәм җайланмасы белән тәэмин итү законнар нигезендә башка предприятиеләр һәм оешмалар тарфыннан да башкарылырга мөмкин.

23 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария хезмәте белгечләренә социаль гарантияләр**

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә ветеринария табибләренә һәм фельдшерларына биш елдан артык өзелмәс стаж өчен – хезмәт окладының 10 проценты, 10 елдан артык – 25 проценты, 25 елдан артык стаж өчен 50 проценты күләмендә өстәлмә билгеләнә.».

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2005 елның 19 июле

№ 89-ТРЗ